| МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

30.11.2016 № 1368-п

Шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан тыш) эшчәнлек процессында региональ дәүләт экологик күзәтчелегенә караучы объектларда калдыклар барлыкка килә торган хуҗалык һәм (яки) бүтән төр эшчәнлегенә карата кулланылучы калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында

1998 елның 24 июнендәге № 89-ФЗ "Җитештерү һәм куллану калдыклары турында" Федераль законның 6 маддәсен үтәү өчен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы "Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре" карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турында Нигезләмәгә туры китереп, хуҗалык яки бүтән төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын җайга салу максатларында боерык бирәм:

1. Кушымтага туры китереп, Шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан тыш) эшчәнлек процессында региональ дәүләт экологик күзәтчелегенә караучы объектларда калдыклар барлыкка килә торган хуҗалык һәм (яки) бүтән төр эшчәнлегенә карата кулланылучы калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләрне расларга.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Р.И.Камаловка йөкләргә.

Министр Ф.С. Габделганиев

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигый байлыклар
министрлыгының 30.11.2016
№ 1368-п боерыгы белән расланды

**Шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан тыш) эшчәнлек процессында региональ дәүләт экологик күзәтчелегенә караучы объектларда калдыклар барлыкка килә торган хуҗалык һәм (яки) бүтән төр эшчәнлегенә карата кулланылучы калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләү буенча**

# МЕТОДИК КҮРСӘТМӘЛӘР

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Шәхси эшмәкәрләрнең, юридик затларның (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан тыш) эшчәнлек процессында региональ дәүләт экологик күзәтчелегенә караучы объектларда калдыклар барлыкка килә торган хуҗалык һәм (яки) бүтән төр эшчәнлегенә карата кулланылучы калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләү буенча Методик күрсәтмәләр (алга таба – Методик күрсәтмәләр) хуҗалык һәм (яки) бүтән төр эшчәнлекләре нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, региональ дәүләт экологик күзәтчелегенә караучы объектларда калдыклар барлыкка килә торган шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан тыш) (алга таба – хуҗалык итүче субъектлар) өчен, шулай ук калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитларны билгеләү буенча карар кабул итә торган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы (алга таба – Министрлык) өчен билгеләнә.

2. Методик күрсәтмәләр калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләүгә ярдәм якын килүне һәм эчтәлегенә һәм рәсмиләштерелүенә карата гомуми таләпләрне билгели.

3. Методик күрсәтмәләрнең көче радиоактив калдыклар белән, биологик калдыклар белән һәм медицина калдыклары белән эш итү мәсьәләләренә кагылмый.

4. Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын (алга таба – КБНУЛП) эшләгәндә, түбәндәгеләр исәпкә алына

- файдаланыла торган чималның, материалларның, эшләнмәләрнең күләме, проект куәтен исәпкә алып;
- калдыкларны һәм аларны урнаштыру объектларын инвентарьләштерү нәтиҗәләре;
- әлеге төрдәге калдыкларны утильләштерү һәм зарарсызландыру объектлары булу һәм аларның куәтләре;
- калдыкларны урнаштыру объектларының булуы, булган объектларның сыйдырышлылыгы, куәтләре һәм исәпләнгән эксплуатацияләү срогы;
- калдыкларны урнаштыруга экологик, санитария-гигиена һәм бүтән төр таләпләр;

- урнаштырыла торган калдыкларның ресурс потенциалы саклануны тәэмин итү мөмкинлеге;

- калдыкларны чыгару өчен транспорт партиясенең икътисадый максатчан күләме;

- урнаштыруга күздә тотыла торган калдыкларның әйләнә-тирә мохиткә зарарлы йогынтысының рөхсәт ителгән иң зур чиге;

- территориядә экологик хәл.

5. Хуҗалык итүче субъектлар Методик күрсәтмәләргә 2нче кушымтага туры китереп КБНУЛП эшлиләр һәм рәсмиләштерәләр һәм әлеге проектларны, калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыруга лимитларны бигеләү өчен, кәгазьдә һәм электрон йөртүчедә Министрлыкка тапшыралар.

6. Хуҗалык итүче субъектның Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан филиалы (-лары) һәм аерымланган бүлекчәләре булган очракта, КБНУЛП хуҗалык итүче субъект буенча тулаем яисә һәр филиал һәм аерымланган бүлекчә өчен аерым эшләнә.

КБНУЛПда хуҗалык итүче субъектның хуҗалык итү яки бүтән төр эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә торган калдыкларының Татарстан Республикасыннан читтә урнашкан калдыклар урнаштыру объектларында урнаштырыла торганнары исәпкә алынмый.

Әгәр хуҗалык итүче субъект җитештерү территорияләренең, биналарның яки җиһазларның бер өлешен арендага бирүче сыйфатында чыгыш ясый һәм арендаторга калдыкларны үзенең калдыклар туплау урыннарында тупларга хокук бирсә, арендаторның калдыклары арендага бирүченең КБНУЛПына кертелгән булырга тиеш. Арендатор калдыклар белән эш итү буенча эшчәнлекне мөстәкыйль башкарган очракта, арендаторның бу йөкләмәләрен раслый торган документлар КБНУЛПга кушымта итеп бирелә.

7. Җитештерү булмаган өлкә шәхси эшмәкәрләре һәм юридик затлары өчен калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләү гадиләштерелгән (декларатив) формада башкарылырга мөмкин.

Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проекты гадиләштерелгән (декларатив) формада шәхси эшмәкәрләрдә һәм юридик затларда V, IV, III класслы куркынычлыктагы калдыклар, шулай ук бары тик файдаланылган терекөмешле лампалардан гына гыйбарәт булган I класслы куркынычлыктагы калдыклар барлыкка килгән очракта эшләнә, әгәр:

калдыкларның суммар күләме елга 150 тоннадан артмаса;

III класс куркынычлыктагы калдыкларның массасы барлыка килә торган калдыкларның гомуми массасының 5%ыннан артмаса;

файдаланылган терекөмешле лампаларны җыю һәм экологик куркынычсыз туплау тәртибе аерым каралган булса.

8. КБНУЛП эшләгәндә, төп бурычлар булып тора:

калдыклар барлыкка килүнең еллык нормативларын билгеләү (исәпләү);

калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм җитештерелгән продукция (башкарылган хезмәт күрсәтүләр, үтәлгән эшләр) күләме нигезендә, ел саен барлыкка килә торган калдыклар микъдарен билгеләү (исәпләү);

утильләштерү һәм (яки) зарарсызлау өчен тәкъдим ителә торган калдыклар микъдарен нигезләү;

территориядәге экологик шартларны исәпкә алып, конкрет калдыклар урнаштыру объектларында аерым бер ысул белән, билгеләнгән срокка урнаштыру өчен тәкъдим ителә торган калдыклар күләмен нигезләү.

9. Хисап чорында билгеләнгән калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыруга лимитларны саклауны раслау максатында, хуҗалык итүче субъектлар (аларның филиалы(лары) яки аерымланган бүлекчәләре) тарафыннан ел саен калдыклар белән эш итү буенча Методик күрсәтмәләргә 3нче кушымтага туры китереп рәсмиләштерелгән техник хисап төзелә һәм хәбәр итү тәртибендә Министрлыкка тапшырыла. Калдыклар белән эш итү буенча техник хисап хуҗалык итүче субъектлар тарафыннан кәгазьдә, шулай ук электрон йөртүчедә тапшырыла.

10. Калдыклар белән эш итү буенча техник хисап түбәндәге максатларда төзелә:

хисап чорында барлыкка килгән калдыкларның КБНУЛПда билгеләнгән төрләрен, куркынычлык классларын һәм күләмен раслау;

хисап чорында барлыкка килгән калдыкларны фактик утильләштерүне, зарарсызландыруны, урнаштыруны, башка хуҗалык итүче субъектларга тапшыруны раслау.

11. I – IV класслы куркынычлыктагы калдыкларны җыю, транспортта ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлек алып бара торган юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен КБНУЛПның гамәлдә булу срогы I - IV класслы куркынычлыктагы калдыкларны җыю, транспортта ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлек алып баруга лицензиянең гамәлдә булу срогына билгеләнә.

Калган очракларда КБНУЛПның гамәлдә булу срогы 5 ел тәшкил итә.

## II. Калдыклар барлыкка килү нормативларын билгеләү (исәпләү) алымнары

12. КБНУЛПда калдыкларның конкрет төрләре барлыкка килүнең еллык нормативларын нигезләүләр калдыклар барлыкка килү нормативлары нигезендә бирелә. Еллык нормативлар елга тонналарда күрсәтелә (т/ел).

Калдыклар барлыкка килүнең еллык нормативы калдык барлыкка килү нормативы нигезендә билгеләнә.

Калдыклар барлыкка килү нормативы берәмлек продукция җитештергәндә конкрет төр калдыкларның каралган күләмен билгели, ягъни исәп берәмлегенә калдыклар барлыкка килүнең чагыштырма күрсәткеченннән гыйбарәт, калдыклар барлыкка килү чыгнагына бәйле рәвештә, исәп берәмлеге итеп алынырга мөмкин:

җитештерелгән продукция берәмлеге, файдаланыла торган чимал берәмлеге – җитештерү калдыклары өчен;

ераклык берәмлеге (мәсәлән, километр) - транспорт чараларына хезмәт күрсәтү калдыклары өчен;

мәйдан берәмлеге – территорияләрне җыештыргандагы калдыклар өчен;

кеше – тораклар калдыклары өчен;

кунакханәдә, ашханәдә урын һ.б.ш.

Калдыклар барлыкка килүнең еллык нормативы гомуми рәвештә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ГНо = Но \times Q \qquad (1)$$

анда

ГНо - калдыклар барлыкка килүнең еллык нормативы, т;

Но - калдыклар барлыкка килү нормативы, т/исәп.берәмл.;

Q –аларга карата калдыклар барлыкка килүнең нормативлары исәпләнелгән чыгарыла торган продукциянең, эшкәртелә торган чималның, башкарылган хезмәт күрсәтүләрнең һ.б. еллык күләме.

Техник документациядә алар өчен эксплутация срогы буенча чикләүләр карала торган материалларның һәм әйберләрнең физик яки мораль тузуы нәтиҗәсендә барлыкка килә торган калдыклар барлыкка килүнең еллык нормативлары исәбен, калдыклар барлыкка килү нормативларын алдан билгеләмичә, түбәндәге формула буенча билгеләү рөхсәт ителә:

$$ГНо = Mi / T \qquad (2)$$

анда

Mi – “калдык” халәтенә күчә торган материалларның, эшләнмәләрнең авырлыгы;

T – материалны, эшләнмәне эксплуатацияләү срогы.

13. Калдыклар барлыкка килү нормативларын, калдыклар барлыкка китерүче процессларның үзенчәлегенә һәм исәпләү өчен беренчел мәгълүматларны алу мөмкинлегенә бәйле рәвештә, түбәндәге алымнарны файдаланып билгелиләр:

материал-чимал балансы буенча исәпләү алымы;

калдыклар барлыкка килүнең чагыштырма тармак нормативлары буенча исәпләү алымы;

исәпләүле-аналитик алым;

эксперименталь алым;

калдыклар барлыкка килүнең фактик күләмнәре буенча исәпләү алымы (статистика алымы).

14. Материал-чимал балансы буенча исәпләү алымы

Материал-чимал балансы буенча исәпләү алымы җитештерү калдыклары барлыкка килүне нормалаштырганда төп алым булып тора. Материал-чимал балансы буенча исәпләүне беренчел чималның яки продукциянең зур номенклатурасы белән

характерлана торган җитештерүләрдә калдыклар барлыкка килү нормативларын билгеләгәндә кулланалар. Исәпләү өчен беренчел мәгълүматлар булып тора:

файдаланыла торган чимал һәм материалларның вакыт берәмлегенә күләме;

чимал һәм материалларның продукциягә күчкән күләме;

җитештерелгән продукция күләме;

табигый кимү нормалары;

атмосфера һавасына чыгарып ташлана торган һәм агынты сулар белән агызып чыгарыла торган матдәләр күләме.

Исәпләү өчен беренчел мәгълүматлар сыйфатында технологик карталар, рецептуралар тасвирнамәсе, технологик регламентлар һәм чимал һәм материаллар файдалануны регламентлый торган башка документлар, чимал һәм материаллар чыгымын, продукция алуны учетка алу материаллары, пычраткыч матдәләр ташлау, агызып чыгару чыганакларын, калдыклар барлыкка килү чыганакларын инвентарьлаштыру нәтиҗәләре, ташлау, агызып чыгару һәм калдыклар барлыкка килүне контрольдә тоту мәгълүматлары файдаланыла. Беренчел чыганаклар Методик күрсәтмәләргә 1нче кушымтаның 1.1 үрнәгенә туры китереп, таблица рәвешендә теркәлә.

Беренчел мәгълүматларның булган җыелмасына бәйле рәвештә, калдыклар барлыкка килү нормативларын исәпләү берничә вариант буенча башкарылырга мөмкин.

Калдыклар күләме һәм вакыт берәмлеге эчендә чыгарыла торган продукция буенча мәгълүматлар булган очракта, калдыклар барлыкка килү нормативы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$H_0 = O / q, \qquad (3)$$

анда

Но - калдыклар барлыкка килү нормативы, т/продукция берәмл.;

О – вакыт берәмлеге эчендә барлыкка килә торган калдык микъдаре тонналарда;

q - вакыт берәмлеге эчендә чыгарыла торган продукция күләме.

Вакыт берәмлеге эчендәге калдык микъдаре буенча мәгълүматлар булмаган, әмма нинди күләмдәге чимал һәм материалларның продукциягә күчүе билгеле булган очракта, вакыт берәмлеге эчендә барлыкка килә торган барлык калдыкларның суммасы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$\Sigma O = \Sigma N - \Sigma P - \Sigma Hn - \Sigma B - \Sigma C \qquad (4)$$

анда

$\Sigma O$ - вакыт берәмлеге эчендә барлык калдыкларның суммасы, т;

$\Sigma N$ - вакыт берәмлеге эчендә җитештерүгә кергән чималның һәм материалларның суммар күләме, т;

$\Sigma P$ - җитештерү процессында вакыт берәмлеге эчендә продукциягә китә торган чималның һәм материалларның суммар күләме, т;

$\Sigma Hn$ - җитештерү процессында вакыт берәмлеге эчендә чималның (материалларның) котылгысыз кире кайтаргысыз югалышы суммасы, т;

$\Sigma B$ - вакыт берәмлеге эчендә атмосфера һавасына чыгармалар составында пычраткыч матдәләрнең суммар күләме, т;

$\Sigma C$ - вакыт берәмлеге эчендә агынтылар составында пычраткыч матдәләрнең суммар күләме, т.

Бу очракта калдыклар барлыкка килү нормативы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Ho = \Sigma O/q \qquad (5)$$

Продукциягә күчә торган чималның һәм материалларның күләме билгеле булмаган, әмма вакыт берәмлеге эчендә чыгарыла торган продукциянең күләме билгеле булган очракта, 4нче формулада $\Sigma P$ зурлыгы $\Sigma q$ белән алыштырыла, ул вакыт берәмлеге эчендә тонналарда чыгарыла торган продукциянең суммар күләменнән гыйбарәт.

Берничә төр продукция җитештергәндә бер төрдәге калдыклар барлыкка килә торган аерым очракларда, калдыклар барлыкка килүнең төркемле нормативын файдаланырга мөмкин, ул тулай продукция берәмлегенә чагыштырма калдыклар барлыкка килүеннән гыйбарәт. Калдыклар барлыкка килүнең төркемле нормативын исәпләү өчен, башта калдыклар барлыкка килүнең суммар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$CO_{отх} = \sum_{i=1}^{i=m} Hi \times q_i \qquad (6)$$

анда

$CO_{отх}$ - калдыклар барлыкка килүнең гомуми суммар күләме;

Hi – һәр төр продукцияне җитештергәндә, калдыклар барлыкка китерүче процесста калдыклар барлыкка килү нормативы, т;

$q_i$ - i төр продукция чыгару күләме;

i – җитештерелә торган продукция төренең индексы (i = 1, 2, 3, 4...m).

Җитештерелә торган тулай продукция берәмлегенә калдыклар барлыкка килүнең уртача үлчәнгән (төркемле) нормативы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Ho\ гр = CO_{отх} / \sum_{i=1}^{i=m} q_i \qquad (7)$$

Әгәр калдыклар барлыкка килү нормативларын исәпләү өчен кирәкле мәгълүматлар югарыда күрсәтелгән документларда булмаса, аларны алу өчен натурадан үлчәүләр үткәрелә.

15. Калдыклар барлыкка килүнең чагыштырма тармак нормативлары буенча исәпләү алымы.

Калдыклар барлыкка килүнең чагыштырма тармак нормативлары буенча исәпләү алымы сәнәгать тармаклары буенча калдыклар барлыкка килүнең чагыштырма нормативлары белешмәлек таблицаларын яисә тармакның норматив документлары белән билгеләнгән калдыклар барлыкка килүнең чагыштырма тармак нормативларын куллануга нигезләнә.

Калдыклар барлыкка килүнең чагыштырма тармак нормативлары эшләнә:

тармак оешмалары өчен калдыклар барлыкка килү нормативларының индивидуаль күрсәткечләрен уртачаландыру юлы белән;

уртача чагыштырма күрсәткечләрне билгеләнгән (база) чор өчен хисап мәгълүматын анализлау, иң мөһим (эксперт рәвештә билгеләнә торган) нормаясагыч факторларны аеру һәм планлаштырыла торган чорга нормативлар күрсәткеченә аларның йогынтысын билгеләү нигезендә исәпләү ысулы белән.

16. Исәпләүле-аналитик алым.

Барышында калдыклар барлыкка килә торган продукция җитештерүгә конструктор-технологик документлар (технологик карталар, рецептуралар, регламентлар, эш сызымнары) булган очракта кулланыла. Андый документлар нигезендә, чимал (материаллар) чыгымының билгеләнгән нормаларына туры китереп, калдыклар барлыкка килү нормативы (Н_о) продукция берәмлегенә чимал (материаллар) чыгымы нормасының һәм, чималның котылгысыз кире кайтаргысыз югалышын исәпкә алып, аларның чиста (файдалы) чыгымының аермасы буларак исәпләнә.

Исәпләү түбәндәге формула буенча башкарыла:

$$Н_о = N - Р_п - Н, \quad (8)$$

анда

N – продукция берәмлегенә чимал (материаллар) чыгымы нормасы, т;

Р – җитештерү процессын (эшне) башкару өчен кирәкле чимал (материаллар) чыгымы, т;

$Н_п$ - җитештерүнең n процесы барышында чималның (материалларның) котылгысыз кире кайтаргысыз югалышлары, т.

Калдыклар барлыкка килү нормативы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Н_о = N\,(1 - К_п) - Р, \quad (9)$$

анда

$К_п = Н_п / N$ - чималның (материалларның) котылгысыз югалышлары коэффициенты.

Калдыклар барлыкка килү нормативы процентларда яки икенчел чимал коэффициенты буларак (Н(1)_о) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$H_o^1 = (1 - K_{исп.} - K_п) \times 100\%, \quad (10)$$

анда

$K_{исп.}$ - продукция җитештергәндә чимал (материаллар) файдалану коэффициенты (K_исп.= P/N).

(8)-(10) формулалары буенча калдыкларның һәр төре барлыкка килү нормативлары билгеләнә.

Тулай җитештерелә торган продукция берәмлегенә калдыклар барлыкка килүнең уртачаүлчәнгән (төркемле) нормативлары түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$H_{o\,гр.} = \frac{\sum_{i=1}^{m}(N_i \times q_i) - \sum_{i=1}^{m}(P_i + H_{пi}) \times q_i}{\sum_{i=1}^{m} q_i} \quad (11)$$

анда

$q_i$ - җитештерелә торган әлеге төр продукция күләме;

i - җитештерелә торган продукция төренең индексы (i - 1, 2, ... m).

Калдыклар барлыкка килү нормативларын исәпләүле-аналитик алым белән исәпләү нәтиҗәләре Методик күрсәтмәләргә 1нче кушымтаның 1.2, 1.3 һәм 1.4 үрнәкләре нигезендә таблица рәвешендә рәсмиләштерелә.

17. Эксперименталь алым.

Чималның состав элементларының билгеле бер диапазондагы үзгәрешләре рөхсәт ителә торган технологик процесслар өчен (металл кою производствосында, сәнәгатьнең химия, азык-төлек, микробиология һәм башка тармакларында), шулай ук аналитик исәпләүләр зур көч таләп итә торган очракта, эксперименталь алым кулланыла, ул калдыклар барлыкка килү нормативларын производство шартларында тәҗрибә үлчәүләре үткәрү нигезендә билгеләүдән гыйбарәт. Башта чимал (материаллар) массасы берәмлегеннән алына торган файдалы продукт массасының тәҗрибә үткәреп алынган үлчәнешләрен статистик эшкәртү нигезендә, чимал берәмлегендә файдалы продукт өлешен характерлый торган күрсәткеч (C_nn) процентларда билгеләнә. Бу күрсәткеч зурлыгыннан һәм чималдан чыгарылган файдалы продукт массасы турында мәгълүматлардан (M_nn) чыгып, калдыклар барлыкка килү массасы (V_o) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_o = M_{пп} \times \frac{100\% - C}{C}. \quad (12)$$

Җитештерелгән продукция берәмлегенә калдык барлыкка килү нормативы (H(11)_o) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$H_0^{11} = \frac{V_0}{Q_{пр.}}, \quad (13)$$

анда

$Q_{пр.}$ - аны җитештергәндә, җитештерү калдыгы барлыкка килә торган продукция микъдаре.

Үзләштерү стадиясендә булган эшләнмәләр өчен калдыклар барлыкка килү нормативлары продукциянең аеруча типик төрләрен җитештергәндә калдыклар массасын үлчәү һәм продукциянең әлеге төре буенча уртача күрсәткечләрне билгеләү нигезендә экспериментль юл белән билгеләнә.

18. Калдыклар барлыкка килүнең фактик күләмнәре буенча исәпләү алымы (статистика алымы).

Алым калдыклар барлыкка килү нормативларын база (3 елдан ким булмаган) чорында калдыклар белән эш итү буенча мәгълүматны статистик эшкәртү нигезендә билгеләү өчен кулланыла.

Калдыклар барлыкка килү нормативларын исәпләү өчен, чимал яки продукция чыганагын һәм нормативны исәпләү нәтиҗәләрен таблица рәвешендә формалаштыралар. Бу очракта башта карала торган чор өчен һәр ел буенча калдыклар барлыкка килүнең чагыштырма күләмен билгелиләр. Калдыклар барлыкка килүнең чагыштырма күләме барлыкка килгән калдыклар күләмен (13-15 графалар) файдаланылган чимал (3-5 графалар) яки җитештерелгән продукция (8-10 графалар) күләменә бүлү юлы белән табыла. Калдыклар барлыкка килү нормативы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Ho = \sum_{i=1}^{i=m} Hoi/T \quad (14)$$

анда

$Hoi$ - і-нчы елда барлыкка килгән калдыкның чагыштырма күләме;

$T$ - карала торган чорда еллар саны.

Башка теләсә нинди исәпләү берәмлеге (ераклык, мәйдан, кеше һ.б.ш.) буенча калдыклар барлыкка килү нормативы шул рәвешле исәпләнә.

Алым калдыклар барлыкка килү нормативларын база (3-еллык) чоры өчен хисап мәгълүматын статистик эшкәртү нигезендә, аннан соң мәгълүматларны җитештерелә торган продукциянең материалсыйдырышлыгын киметүне күздә тотып планлаштырыла торган оештыру-техник чараларга туры китереп төзәтеп, билгеләү өчен кулланыла.

## III. Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проекты эчтәлеге һәм рәсмиләштерелүе

19. Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проекты түбәндәге бүлекләрне эченә ала:

әлеге Методик күрсәтмәләргә 2нче кушымтага туры китереп эшләнә торган титул бите;

эчтәлек, анда КБНУЛП бүлекләренең атамасы һәм урнашу эзлеклелеге бит номерларын күрсәтеп бирелә;

аннотация;

шәхси эшмәкәр яки юридик зат турында гомуми мәгълүматлар;

аны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә калдыклар барлыкка килә торган хуҗалык эшчәнлеге һәм (яки) бүтән төр эшчәнлек турында мәгълүматлар;

калдыклар турында мәгълүматлар;

калдыклар барлыкка килүнең еллык нормативларын исәпләү һәм нигезләү; калдыкларның операция хәрәкәте схемасы;

калдыкларны файдалану һәм (яки) зарарсызлау турында мәгълүматлар;

калдыкларны 11 айга кадәр срок белән саклауның характеристикасы һәм калдыклар тупланунын иң зур чик күләмен нигезләү;

калдыкларны 11 айдан артык срок саклауның һәм калдыкларны күмүнең характеристикасы;

калдыкларны урнаштыру обектлары территорияләрендә һәм аларның әйләнә-тирә табигый мохиткә йогынты ясау чикләре эчендә аларның әйләнә-тирә табигый мохит хәлен мониторинглау;

калдыклар барлыкка килү һәм урнаштыру күләмен киметү, калдыклар белән эш итү өлкәсендә гамәлдәге нормаларны һәм кагыйдәләрне саклауны тәэмин итү буенча мероприятиеләр планы, авариягә каршы чаралар турында мәгълүматлар;

калдыкларны урнаштыруга лимитлар буенча тәкъдимнәр;

файдаланылган әдәбият исемлеге;

кушымталар.

20. КБНУЛПның “Аннотация"бүлегендә күрсәтелә:

юридик затның атамасы яки шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының исеме;

хуҗалык һәм бүтән төр эшчәнлегенең төп профиле;

I - IV класслы куркынычлыктагы калдыкларны җыю, транспортта ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлек алып баруга лицензиянең реквизитлары (I - IV класслы куркынычлыктагы калдыкларны җыю, транспортта ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлек алып баручы шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар өчен);

барлыкка килә торган калдыклар күләме, аларның куркынычлык класслары буенча;

калдыкларны туплау объектлары саны;

калдыклар урнаштыру объектларының булуы турында мәгълүмат;

утильләштерелергә, зарарсызланырга, урнаштырылырга тиешле калдыкларның күләме, куркынычлык класслары буенча;

калдыклар белән эш итү өлкәсендә планлаштырыла торган чаралар турында мәгълүмат;

КБНУЛП эшләүчесе турында мәгълүматлар.

21. КБНУЛПның “Шәхси эшмәкәр яки юридик зат турында гомуми мәгълүматлар” бүлегендә бирелә:

юридик затның тулы һәм (булган очракта) кыскартылган атамасы, шул исәптән фирма атамасы, оештыру-хокук формасы, аның урнашкан урыны, юридик затны оештыру турында  язуның дәүләт теркәве номеры һәм юридик зат турында язуны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына (ЕГРЮЛ) кертү фактын раслый тораган документ мәгълүматлары – юридик зат өчен;

шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, яшәү урыны, шәхесен таныклый торган документ мәгълүматлары, шәхси эшмәкәр сыйфатында дәүләт теркәвенә алу турында язуның дәүләт теркәве номеры һәм шәхси эшмәкәр турында язуны Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрына (ЕГРИП) кертү фактын раслый торган документ мәгълүматлары - шәхси эшмәкәр өчен;

территориаль аерымланган бүлекчәләр (филиаллар) турында мәгълүматлар;

юридик затның һәм аның территориаль аерымланган бүлекчәләренең (филиалларының) юридик һәм фактик адресы;

юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең телефон, факс номерлары, электрон почта адресы;

юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең салым органында учетка куелуы турында мәгълүматлар – салым түләүченең идентификация номеры, учетка кую датасы, таныклыкның сериясе һәм номеры;

ОКПО, ОКОПФ, ОКФС, ОКВЭД кодлары;

эшчәнлекнең төп юнәлешләре турында мәгълүматлар (чит оешмалардан һәм гражданнардан калдыклар җыю, транспортта ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызлау, урнаштыруга юнәлтелгән икътисадый эшчәнлек төрләре өчен кабул ителә торган калдыкларның төрләре һәм күләмнәре турында һәм калдыклар белән эш итү буенча бөтен операцияләр турында мәгълүмат күрсәтелә);

эшнең төп җитештерү күрсәткечләре, шул исәптән чыгарыла торган продукция күләме;

персоналның штаттагы һәм фактик саны;

структур бүлекчәләр исемлеге;

милектә, биләмәдә, файдалануда булган калдыклар саклау һәм күмү объектларының булуы;

шәхси эшмәкәрнең яки юридик затның объектларында калдыклар туплый торган арендаторлар исемлеге.

22. КБНУЛП “Гамәлгә ашырылуы нәтиҗәсендә калдыклар барлыкка килә торган хуҗалык эшчәнлеге һәм бүтән төр эшчәнлек турында мәгълүматлар” бүлегендә аны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә калдыклар барлыкка килә торган хуҗалык эшчәнлеге яки бүтән төр эшчәнлек турында мәгълүматлар күрсәтелә, шулай ук җитештерү процессларына калдыклар барлыкка килү чыганаклары буларак характеристика бирелә.

Продукция җитештерүгә юнәлтелгән икътисадый эшчәнлек төрләре өчен чималның төп төрләре, җитештерелә торган продукция, объектларның производство куәтләре турында мәгълүмат күрсәтелә.

Хезмәт күрсәтүгә юнәлтелгән икътисадый эшчәнлек төрләре өчен күрсәтелә торган хезмәтләрнең төрләре һәм күләмнәре (ташыла торган йөкнең күләме, барулар саны, койко-урын саны һ.б.) күрсәтелә

Бүлектә оешма структурасына кыскача характеристика китерелә, продукция җитештерү буенча, төзелеш элементлары һәм биналарны эксплуатацияләү өчен кирәкле җиһаз урнаштыру һәм (яки) монтажлау буенча, приборларга, аппаратурага, машиналарга, җиһазга, транспорт чараларына һ.б. техник хезмәт күрсәтү һәм (яки) ремонтлау буенча, көнкүреш эшләнмәләренә һәм шәхси файдалану әйберләренә, офис машиналарына һәм исәпләү техникасына техник хезмәт күрсәтү һәм (яки) ремонтлау буенча эшчәнлекне, аналитик контроль буенча һ.б. эшчәнлекне гамәлгә ашыручы бүлекчәләрне, шулай ук социаль инфраструктура объектларын (медсанчасть һәм сәламәтлек пунктлары, җәмәгать туклануы объектларын, кибетләр һ.б.) да кертеп.

Җитештерү процесслары турында калдыклар барлыкка килү чыганаклары буларак күрсәткән мәгълүматлар һәр җитештерү участогы буенча текст формасында яки блок-схемалар рәвешендә тапшырыла.

КБНУЛПга алар буенча мәгълүмат кертелгән һәр структур бүлекчә (цех, участок һ.б.ш.) буенча технологик процессларның блок-схемалары тапшырыла, алар үз эченә аерым блоклар рәвешендә түбәндәгеләрне ала:

файдаланыла торган чимал, материаллар, ярымфабрикатлар, бүтәннәрне;

җитештерү операцияләрен;

җитештерелә торган продукцияне (күрсәтелә торган хезмәтләр, башкарыла торган эшләр);

барлыкка килә торган калдыкларны (чыгышы яки барлыкка килү шартлары буенча);

калдыклар белән эш итү буенча калдыкларны утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыруны, калдыкларны башка структур бүлекчәләргә яки башка хуҗалык итүче субъектларга тапшыруны үз эченә ала торган алдагы операцияләрне.

Продукция җитештергәндә, эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә ашырганда калдыклар барлыкка килү турында мәгълүмат КБНУЛПда Методик күрсәтмәләргә 2нче кушымтаның 2.2 - 2.4 үрнәкләре нигезендә тапшырыла. КБНУЛПның бу бүлеген әзерләү өчен чыганак булып калдыкларны инвентаризацияләү нәтиҗәләре тора.

Төп эшчәнлекләре чит оешмалардан һәм гражданнардан калдыклар җыю, транспортта ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру булган шәхси эшмәкәрләр һәм юридик затлар бу бүлектә кабул ителә торган калдыкларның күләме һәм характеристикасы турында һәм калдыклар белән эш итү буенча барлык операцияләр турында мәгълүмат күрсәтәләр.

Бүлек ахырында алар өчен еллык барлыкка килү нормативы билгеләнә торган барлыкка килә торган калдыкларның җыелма исемлеге бирелә. Исемлек Методик күрсәтмәләргә 2нче кушымтаның 2.5 үрнәгенә туры китереп рәсмиләштерелә.

Россия Табигать министрлыгының 2011 елның 30 сентябрендәге № 792 боерыгы белән расланган Калдыкларның дәүләт кадастрын алып бару тәртибе нигезендә Ростабигать күзәтчелеге тарафыннан формалаштырыла торган Калдыкларның федераль классификация каталогына (алга таба - ФККО) кертелмәгән барлык калдыклар өчен, Россия Табигать министрлыгының 2014 елның 5 декабрендәге №541 боерыгы белән расланган I - IV класслы куркынычлыктагы калдыкларны конкрет куркынычлык классына кертү тәртибе һәм (яки) калдыкларны I - V куркынычлыктагы классларга әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты дәрәҗәсе буенча кертү критерийларына туры китереп, куркынычлык классы күрсәтелә

Шул ук вакытта КБНУЛПга кушымтада хуҗалык итүче субъект тарафыннан Ростабигать күзәтчелегенең тиешле территориаль органынына калдык төрен конкрет куркынычлык классына кертүне раслый торган документлар җибәрү турында хатның реквизитлары күрсәтелә.

23. КБНУЛПның "Калдыклар турында мәгълүматлар" бүлегендә, составы, калдыкларның физик-химик характеристикалары, әйләнә-тирә табигый мохит өчен куркынычлык класслары турында мәгълүматлар күрсәтеп, барлыкка килә һәм (яки) утильләштерүгә, зарарсызландыруга, урнаштыруга кабул ителә торган калдыклар исемлеге китерелә.

Күрсәтелгән мәгълүматлар 2нче кушымтаның 2.6 үрнәгенә туры китереп бирелә, хуҗалык итүче субъект тарафыннан барлыкка китерелә торган калдыклар өчен – калдыкларның паспортлары, калдыкларның куркынычлык классларын һәм аларның куркыныч үзенчәлекләрен дәлилләү материаллары нигезендә; утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыруга кабул ителә торган калдыклар өчен – калдыкларны китерүчеләр тарафыннан күрсәтелә торган калдыклар паспортлары нигезендә.

Бүлекнең текст өлешендә, файдаланылган алымнарны күрсәтеп, калдыкларның куркынычлык классларын һәм аларның физик-химик үзенчәлекләрен билгеләү буенча башкарылган эшләр турында мәгълүматлар китерелә. КБНУЛПга кушымтада хуҗалык итүче субъект тарафыннан Ростабигать күзәтчелегенең тиешле территориаль органынына калдыкның төрен конкрет куркынычлык классына кертүне раслый торган документлар җибәрү турында хатның реквизитлары күрсәтелә.

24. КБНУЛПның "Калдыклар барлыкка килүнең еллык нормативларын исәпләү һәм нигезләү" бүлегендә Методик күрсәтмәләрнең II бүлегендә китерелгән калдыклар барлыкка килү нормативларын билгеләү (исәпләү) алымнарын файдаланып, һәр төр калдык өчен исәпләнгән (билгеләнгән) калдыклар барлыкка килү нормативы исәпләре күрсәтелә.

Калдыкның һәр төре өчен нормативлар исәбен аерым бүлекчәдә рәсмиләштерәләр.

Материал-чимал балансы, исәпләүле-аналитик һәм статистик алымнар белән башкарыла торган исәпләүләр өчен беренчел чыганакларны Методик күрсәтмәләргә 1нче кушымта нигезендә таблица рәвешендә тапшырырга тәкъдим ителә. Чагыштырма күрсәткечләр буенча исәпләү алымын файдаланганда, исәпләүләрне һәм нигезләүләрне текст формасында тапшыру рөхсәт ителә.

Текст формасында калдыкның һәр төре буенча тиешле мәгълүмат чыганакларына сылтамалар, шулай ук теге яки бу микъдари күрсәткечләрне таныклый торган кушымталар бирелә.

Шәхси эшмәкәрдә яки юридик затта хуҗалык-көнкүреш һәм сәнәгать агынты сулары өчен чистарту корылмалары яки су әзерләү җиһазы һәм җайланмалары, шулай ук тузан тотып калучы һәм газчистарткыч җайланмалар һәм җиһазлар булган очракта, Методик күрсәтмәләргә 2нче кушымтаның 2.7, 2.8, 2.9 үрнәкләренә туры китереп, аларның характеристикаларын тапшырырга кирәк. Югарыда саналып киткән корылмаларны, җайланмаларны, җиһазны эксплуатацияләгәндә барлыкка килә торган калдыклар калдыкларның гомуми исемлегенә кертелә.

Бүлек ахырында исәпләүләр нәтиҗәләре буенча барлыкка килә торган калдыкларның гомуми исемлеге формалаштырыла, 2нче кушымтаның 2.10 үрнәгенә туры китереп исәпләнгән калдыклар барлыкка килүнең еллык нормативларын күрсәтеп.

25. КБНУЛПның “Калдыкларның операция хәрәкәте схемасы” бүлегендә калдыклар барлыкка килү, калдыкларны файдалану буенча, калдыкларны эшкәртү, зарарсызландыру һәм/яки күмү максатында башка оешмаларга бирү буенча мәгълүматлар бирелә, калдыкларны китерүчеләрнең һәм кулланучыларның адреслары һәм реквизитлары күрсәтелә.

КБНУЛПның бу бүлегенең максаты булып калдыкларның һәр төре белән эш итү (барлыкка килү, утильләштерү, зарарсызландыру, кабул итү, тапшыру, урнаштыру) буенча мәгълүмат тапшыру тора.

Калдыкларның операция хәрәкәте схемасы һәм калдыкларны китереп торучылар һәм кулланучылар турында реквизитлар (мәгълүматлар) турында информация 2нче кушымтаның 2.11 һәм 2.12 үрәкләренә туры китереп, таблица рәвешендә бирелә. Калдыкларның һәр төре өчен таблицада аерым юл бирелә. КБНУЛПга кушымтада реквизитлары 2.12 таблицада күрсәтелгән договорларның күчермәләре бирелә.

26. КБНУЛПның “Калдыкларны утильләштерү һәм зарарсызландыру турында мәгълүматлар” бүлегендә хуҗалык итүче субъект тарафыннан гамәлгә ашырыла торган калдыкларны утильләштерү һәм зарарсызландыру турында мәгълүмат бирелә, шулай ук бу вакытта барлыкка килә торган калдыкларның төрләре күрсәтелә. Калдыкларны утильләштерү һәм зарарсызландыру объектларының характеристикасы таблица рәвешендә 2нче кушымтаның 2.13 үрнәге буенча бирелә. Утильләштерү һәм зарарсызландыру җайланмаларында барлыкка килә торган калдыклар калдыкларның гомуми исемлегенә кертелә.

Әгәр хуҗалык итүче субъект калдыкларны утильләштерүне калдыкларны утильләштерү һәм зарарсызландыру объектларын файдаланмыйча гамәлгә ашырса (мәсәлән, чималга, реагентларга өстәмә сыйфатында, юлларга сипкәндә өстәү өчен, хайваннар һәм кошларны асрау өчен асларына түшәмә сыйфатында һ.б.), калдыкларны шулай куллануны регламентлый яки рөхсәт итә торган документлар турында мәгълүмат бирелә (мәсәлән, предприятиенең техник документациясе, шул исәптән предприятие стандартлары, техник регламентлары, ведомствоның норматив

документлары, дәүләт күзәтчелеге органнарынан махсус алынган килешенүләр яки бәяләмәләр).

27. КБНУЛПның “Калдыкларны 11 айга кадәр срок белән саклауның характеристикасы һәм калдыклар тупланунының иң зур чик күләмен нигезләү” бүлеге.

Калдыкларны 11 айга кадәр срок белән саклау – калдыкларны, соңыннан утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыруга тапшырып, түбәндәгеләрне исәпкә алып билгеләнгән 11 айдан артмаган срок дәвамында саклау: санитария-гигиена, янгын куркынычсызлыгы һәм бүтән таләпләрне, нормалар, кагыйдәләрне; утильләштерү һәм зарарсызландыру, калдыклар партиясе формалашу вакытын; калдыкларны транспортлау партиясе формалашу вакытын.

Әгәр хуҗалык итүче субъект калдыклар барлыкка китерү, җыюны һәм аларны, соңыннан утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыруга тапшырып, 11 айдан артмаган вакыт дәвамында туплауны гамәлгә ашырса, КБНУЛПның бу бүлегендә калдыклар туплауның иң зур чик күләмен нигезләүләр бирелә (бер типтагы саклау объектларында бер үк вакытта 1 айга кадәр срокта саклана торган аерым төр калдыкларның җыелма күләме, әйләнә-тирә мохиткә йогынты дәрәҗәсенең рөхсәт ителгән чикләрен тәэмин иткән шартта).

Калдыкларны саклау объектларында 11 айга кадәр срок белән туплауның иң зур чик күләмен нигезләгәндә, хуҗалык итүче субъектлар тиеш:

- урнаштырыла торган калдыкның һәр төре өчен саклауның сәбәбен формалаштырырга: транспортлау партиясен туплау, утильләштерү һәм зарарсызландыру өчен партия туплау, калдыкларның куркынычлык классын түбәнәйтү, ресурс тәшкил итүчеләрне аеру һ.б.;
- калдыкның һәр төре өчен туплау срогын һәм туплау күләменең иң зур чиген нигезләргә;
- 1-2 класслы куркынычлыктагы куркыныч матдәләрне эченә алган һәм янгын куркынычлыгы, шартлау куркынычлыгы кебек куркыныч үзлекләре булган куркыныч калдыклар өчен, калдыкларны туплау күләменең иң зур чиге зурлыгы буенча, матдәләрне һәм материалларны саклау куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча гамәлдәге норматив документлар нигезендә, чикләүләр кертү кирәклеген карарга;
- һәр туплау объекты өчен яки бертиплы объектлар төркеме өчен калдыкларны туплау ысулының, объектларның булган җиһазланылышының, урнаштыру өчен файдаланыла торган тараның гамәлдәге нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килүен карарга.

Калдыклар туплау объектларының ачык мәйданчык, каплаулы мәйданчык, бина, стационар сыешлык кебек типларга карый торганнары турында мәгълүматлар, калдыклар туплауның иң зур чик күләмен күрсәтеп, 2нче кушымтаның 2.14 үрнәгенә туры китереп, таблица рәвешендә бирелә. Бертиплы объектлар, аларның санын һәм җиһазланышы һәм саклау ысуллары буенча гомуми характеристикаларын күрсәтеп, бер юлда бирелә. Шул ук вакытта 2нче кушымтаның 2.14 үрнәге буенча таблицаның 5 һәм 6 графаларында аларның суммар сыйдырышлыгы күрсәтелә.

Калдыкларны 11 айга кадәр срок белән туплау буенча калган объектлар турында мәгълүматлар 2нче кушымтаның 2.15 үрнәгенә туры китереп, таблица рәвешендә бирелә. Бүлек текстында калдыкларны туплау срогы турында мәгълүмат һәм туплау срогын һәм бу объектлардан калдыкларны алып китү периодиклыгын нигезләү бирелә.

28. КБНУЛПның “Калдыкларны 11 айдан артык саклауның һәм калдыкларны күмүнең характеристикасы” бүлеге.

Хуҗалык итүче субъектның утильләштерелергә һәм зарарсызландырылырга тиеш булмаган, ә 3 елдан артыграк срокта саклауны яки күмүне таләп итә торган калдыклары булса, бу бүлектә әлеге калдыкларны урнаштыруга лимитлар зурлыгын нигезләүләр бирелә.

Калдыкларны саклау объектларына 3 елдан артыграк срокка урнаштыруга һәм күмүгә лимитларны нигезләгәндә, хуҗалык итүче субъектлар тиеш:

-калдыкларны урнаштыру зарурлыгын нигезләргә (әлеге территориядә калдыкларны эшкәртү буенча махсуслаштырылган предприятиеләрнең булмавы, калдыкларны эшкәртүнең икътисадый яраклы технологияләре булмау һ.б.);

- калдыкның һәр төре өчен сорала торган лимитның зурлыгын нигезләргә;

- табигать саклау мероприятиеләре планына урнаштырылырга тиешле калдыклар барлыкка килүне киметү буенча, урнаштыруга җибәрелә торган калдыклар күләмен киметү буенча чаралар кертү мөмкинлеген карарга.

Калдыкларны үз урнаштыру объектларына урнаштырганда, өстәмә рәвештә тиеш:

-кулланыла торган калдыкларны урнаштыру чарасының, объектларының булган җиһазланышының, урнаштыру өчен файдаланыла торган тараның гамәлдәге норма һәм кагыйдәләргә туры килүен карарга;

- калдыкларны объектта урнаштырганда, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтының мөмкин булган факторларын карарга;

- әйләнә-тирә мохит хәлен контрольдә тоту системасына характеристика бирергә, гамәлдә булган объектлар өчен әйләнә-тирә мохиткә йогынты яравын мониторинг нәтиҗәләре буенча бәяләргә

Калдыкларны хуҗалык итүче субъект милегендә, биләмәсендә торган объектларда урнаштырган очракта, 2нче кушымтаның 2.15 үрнәгенә туры китереп, бу объектлар турында мәгълүмат бирелә.

29. КБНУЛПның “Калдыкларны урнаштыру объектлары территорияләрендә һәм аларның әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясау чикләрендә әйләнә-тирә мохит хәлен мониторинглау” бүлегендә калдыкларны урнаштыру объектлары (3 елдан артык саклау һәм күмү объектлары) территориясендә әйләнә-тирә мохит хәлен күзәтү буенча мероприятиеләр турында мәгълүмат, шулай ук калдыкларны урнаштыру объектлары территориясендә һәм аларның әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясау чикләрендә әйләнә-тирә мохит хәленә мониторинг үткәрү нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирелә.

Әйләнә-тирә мохит хәле турында мәгълүмат түбәндәгеләрне күрсәтеп тапшырыла:

- контроль үлчәүләр алу объектлары һәм нокталары, әйләнә-тирә мохит компонентлары буенча пычраткыч матдәләр пробаларын алу ешлыгы;

- әгәр контроль үлчәүләр алу өчен чит оешмалар җәлеп ителсә, оешманың исеме, лабораториянең аттестациясе һәм аккредитациясе турында мәгълүматлар күрсәтелә, КБНУЛПга кушымтада тиешле договорның күчермәсе китерелә;

- соңгы 2-3 елда контроль үлчәүләр алулар нәтиҗәләре, әйләнә-тирә мохит сыйфаты нормативларын арттыру очракларын күрсәтеп.

Калдыкларны урнаштыру объектлары территорияләрендә һәм аларның әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясау чикләрендә әйләнә-тирә мохит хәлен мониторинглау нәтиҗәләре турында мәгълүматлар 2нче кушымтаның 2.16 үрнәгенә туры китереп таблица рәвешендә бирелә. КБНУЛПга кушымтада, контроль үлчәүләр алу нокталарын төшереп, ситуация планы, файдаланыла торган контроль һәм үлчәүләр чаралары исемлеге китерелә, аларга поверка үткәрү турында таныклыклар кушымта итеп беркетелә.

30. КБНУЛПның “Калдыклар барлыкка килү һәм урнаштыру күләмен киметү, калдыклар белән эш итү өлкәсендә гамәлдәге нормаларны һәм кагыйдәләрне саклауны тәэмин итү буенча мероприятиеләр планы, авариягә каршы чаралар турында мәгълүматлар” бүлегендә барлыкка килә торган калдыкларның әйләнә-тирә мохит хәленә тискәре йогынтысын киметү буенча үткәрелә торган һәм планлаштырыла торган мероприятиеләр турында информация китерелә. Түбәндәгеләргә юнәлтелгән мероприятиеләр турында мәгълүматлар күрсәтелә:

калдыклар барлыкка килү күләмен киметү;

калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру буенча технологияләр кертү;

гамәлдәге таләпләргә җавап бирми торган калдыклар урнаштыру урыннарын оештырып һәм җиһазлап бетерү;

элек тупланган калдыкларны чыгару;

калдыклар белән эш итүгә производство контроле һәм калдыклар урнаштыру объектлары территорияләрендә әйләнә-тирә мохит хәленә мониторинг үткәрү.

Калдыклар барлыкка килү һәм урнаштыру күләмен киметү, калдыклар белән эш итү өлкәсендә гамәлдәге нормаларны һәм кагыйдәләрне саклауны тәэмин итү буенча мероприятиеләр планнары 2нче кушымтаның 2.17 үрнәгенә туры китереп тапшырыла.

Бүлектә шулай ук куркыныч калдыклар белән эш иткәндә булуы мөмкин булган авария ситуацияләре турында, авариягә каршы мероприятиеләр һәм аварияләрне ликвидацияләү чаралары турында информация күрсәтелә. Информация 2нче кушымтаның 2.18 үрнәгенә туры китереп тапшырыла.

31. КБНУЛПның “Калдыкларны урнаштыруга лимитлар буенча тәкъдимнәр” бүлегендә калдыклар барлыкка килү һәм аларны урнаштыруга лимитлар нормативларын нигезләүләр һәм зурлыклары, 2нче кушымтаның 2.19 үрнәгенә туры китереп, таблица рәвешендә бирелә. Калдыкның һәр төре өчен таблицада аерым юл бирелә.

Калдыклар куркынычлык класслары буенча төркемләнә.

32. КБНУЛПның “Файдаланылган әдәбият исемлеге” бүлеге.

КБНУЛПның әлеге бүлегендә КБНУЛПны әзерләү процессында файдаланылган мәгълүмат чыганаклары: белешмәлекләр, фәнни-техник әдәбият, норматив-методик документация исемлеге, авторларын, нәшриятын һәм басылып чыгу елын күрсәтеп бирелә.

33. КБНУЛПга кушымталар.

КБНУЛПның “Кушымталар” бүлегенә кертелә:

калдыкларның паспортлары күчермәләре;

калдыкларны махсуслаштырылган объектларда урнаштырырга, калдыкларны аларны утильләштерү һәм (яки) зарарсызландыру максаты белән тапшыруны (яки кабул итүне) ниятләүне раслый торган документлар (договорларның, актларның хуҗалык итүче субъект тарафыннан расланган күчермәләре);

калдыкларны утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру фактларын раслый торган документлар (договорларның, актларның хуҗалык итүче субъект тарафыннан расланган күчермәләре);

хуҗалык итүче субъектның калдыкларны утильләштерүе, зарарсызландыруы турында, мөстәкыйль эксплуатацияләү объектларында калдыкларны саклау һәм күмү турында хисап чоры өчен документларның хуҗалык итүче субъект тарафыннан расланган күчермәләре;

калдыкларны утильләштерү, зарарсызландыру, саклау һәм күмү өчен башка хуҗалык итүче субъектларга тапшыру-кабул итү турында хисап чоры өчен договорларның (актларның) хуҗалык итүче субъект тарафыннан расланган күчермәләре;

куркыныч калдыклар аларга милек итеп, яисә биләү, файдалану һәм эш итү хокукында транспортта ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру өчен тапшырыла торган хуҗалык итүче субъектларга I - IV класслы калдыклар җыю, транспортта ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлегенә бирелгән лицензияләрнең реквизитлары;

утильләштерү, зарарсызландыру объектларының һәм предприятие территориясендә калдыклар урнаштыру объектлары урнашуның карта-схемасы, экспликация белән;

калдыкларны урнаштыру объектлары территорияләрендә һәм аларның әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясау чикләрендә әйләнә-тирә мохит хәле мониторингы кысаларындагы котроль үлчәүләр нокталары төшерелгән ситуация планы;

контроль һәм үлчәүләрнең файдаланыла торган чаралары исемлеге;

материал-чимал балансы һәм производство күрсәткечләре мәгълүматларын раслый торган документлар;

арендаторның калдыклар белән эш итү буенча эшчәнлекне, экология һәм санитария-гигиена таләпләрен үтәп, мөстәкыйль гамәлгә ашыру йөкләмәләрен раслый торган документлар (әгәр хуҗалык итүче субъект производство территорияләренең, биналарның яки җиһазларының өлешен арендага бирүче сыйфатында чыкса, һәм арендатор калдыклар белән эш итү буенча мөстәкыйль эшчәнлек алып барса).

34. Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектының (КБНУЛП) гадиләштерелгән (декларатив) формасы үз эченә түбәндәге бүлекләрне ала:

әлеге Методик күрсәтмәләргә 2нче кушымтага туры китереп эшләнә торган титул бите;

эчтәлек, анда КБНУЛП бүлекләренең атамасы һәм урнашу эзлеклелеге бит номерларын күрсәтеп бирелә;

шәхси эшмәкәр яки юридик зат турында гомуми мәгълүматлар;

гамәлгә ашырылуы нәтиҗәсендә калдыклар барлыкка килә торган хуҗалык эшчәнлеге һәм (яки) бүтән төр эшчәнлек турында мәгълүматлар;

калдыклар турында мәгълүматлар;

калдыклар барлыкка килүнең еллык нормативларын исәпләү һәм нигезләү;

калдыкларны урнаштыру лимитлары буенча тәкъдимнәр;

кушымталар.

Әлеге бүлекләр Методик күрсәтмәләрнең тиешле 21-24, 31 һәм 33пунктларына туры китереп рәсмиләштерелә.

35. КБНУЛП битләрен, кушымталарны да кертеп, үтәли нумерация белән нумерлыйлар.

36. КБНУЛПга калдыкларны утильләштерү, зарасызландыру объектларының һәм калдыкларны урнаштыру объектларының учет формаларының аерым комплекты беркетелә (2.13 һәм 2.15 үрнәкләр).

## IV. Калдыклар белән эш итү буенча техник хисапның эчтәлеге һәм рәсмиләштерү

37. Калдыклар белән эш итү буенча техник хисапның (алга таба - Техник хисап) структурасы түбәндәге бүлекләрне үз эченә ала:

титул бите;

җитештерү процессының һәм файдаланыла торган чималның үзгәрешсезлеген раслау;

хисап чоры (ел) барышында калдыклар белән эш итү турында мәгълүматлар;

кушымталар.

38. Техник хисапның титул бите 3нче кушымтаның 3.1 үрнәге буенча рәсмиләшә.

39. Техник хисапның “Җитештерү процессының һәм файдаланыла торган чималның үзгәрешсезлеген раслау” бүлеге 3нче кушымтаның 3.2 үрнәгенә туры китереп рәсмиләшә.

40. Техник хисапның “Хисап чоры барышында калдыклар белән эш итү турында мәгълүматлар” бүлеге үз эченә түбәндәгеләр турында информацияне ала:

хисап чоры өчен барлыкка килгән, утильләштерелгән һәм урнаштырылган калдыклар балансы (3нче кушымтаның 3.3, 3.4 һәм 3.5 үрнәкләренә туры китереп);

хисап чоры өчен калдыкларның әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын киметү буенча мероприятиеләр планының үтәлеше (3нче кушымтаның 3.6 үрнәгенә туры китереп);

хисап чорында эксплуатациягә кертелгән калдыкларны утильләштерү, зарарсызландыру объектлары (2нче кушымтаның 2.13 үрнәгенә туры китереп);

хисап чорында эксплуатациягә кертелгән (эксплуатациядән чыгарылган, рекультивацияләнгән) калдыклар урнаштыру объектлары (2нче кушымтаның 2.14 һәм 2.15 үрнәкләренә туры китереп).

41. Техник хисапка кушымталарда тапшырыла:

хуҗалык итүче субъект тарафыннан калдыкларның утильләштерелүе, зарарсызландырылуы, мөстәкыйль эксплуатацияләү объектларында калдыкларны саклау һәм күмү турында хисап чоры өчен документларның хуҗалык итүче субъект тарафыннан расланган күчермәләре;

калдыкларны транспортта ташуга договорларның күчермәләре, калдыкларны утильләштерүгә, зарарсызландыруга, урнаштыруга тапшыру фактын раслаучы документлар;

калдыкларны утильләштерү, зарарсызландыру, саклау һәм күмү өчен башка хуҗалык итүче субъектларга тапшыру-кабул итү турында хисап чоры өчен договорларның (актларның) хуҗалык итүче субъект тарафыннан расланган күчермәләре;

I - IV класслы куркынычлыктагы калдыклар аларга милек итеп, яисә биләү, файдалану яки эш итү хокукында эшкәртү, утильләштерү, транспортта ташу, зарарсызландыру, урнаштыру өчен тапшырыла торган хуҗалык итүче субъектларга I - IV класслы калдыклар җыю, транспортта ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлеккә бирелгән лицензияләрнең реквизитлары.

Калдыклар барлыкка килү
нормативлары һәм аларны урнаштыруга
лимитлар проектларын эшләү буенча
методик күрсәтмәләргә
Кушымта 1

## Үрнәк 1.1.

## Калдыклар барлыкка килү нормативын материал-чимал балансы буенча исәпләү өчен беренчел мәгълүматлар

| Чимал һәм материаллар исемлеге | т/вакыт берәмл. кирә торган чимал һәм материал микъдаре | | Продукция, т/вакыт берәмл. | Чимал һәм материаллар югалышлары, т/вакыт берәмл. | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | җитештерүгә | продукциягә | | Кире кайтаргысыз югалышлар (табигый киму) | | чыгармалар | агынтылар | калдыклар |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | N | P | q | Кп | Нп | B | C | 0 |

## 1.1. Үрнәк буенча таблицаны тутыру буенча күрсәтмәләр.

**1 графада** җитештерүгә кирә торган чималның һәм материалларның атамасын күрсәтәләр;

**2 графада** җитештерүгә вакыт берәмлеге (күрсәтергә) эчендә кергән чимал һәм материаллар микъдарен тонналарда күрсәтәләр;

**3 графада** җитештерү процессында вакыт берәмл. эчендә продукциягә китә торган материаллар микъдарен тонналарда күрсәтәләр;

**4 графада** вакыт берәмл. эчендә эшләп чыгарыла торган продукция күләмен тонналарда күрсәтәләр;

**5 графада** кире кайтаргысыз югалышларның (табигый кимүнең) коэффициентын күрсәтәләр;

**6 графада** кире кайтаргысыз югалышларны (табигый кимүне) вакыт берәмлеге эчендә тонналарда күрсәтәләр;

**7, 8, 9 графаларда** вакыт берәмлеге эчендә чыгармаларны, агынтыларны һәм калдыкларны тонналарда күрсәтәләр.

**Үрнәк 1.2.**

**Җитештерелә торган продукция берәмлегенә карата билгеләнә торган калдыклар барлыкка килү нормативларын исәпләүле-аналитик алым белән исәпләү**

| Калдык төре | | Продукция | | | | | Чимал яки материаллар | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Атама | ФККО буенча код | Атама | ОКП буенча код | Чыгарыла торган продукциянең планлаштырыла торган күләме ($q_i$) | Үлчәү берәмлеге | | Атама | ОКП буенча код |
| | | | | | Атама | Код | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |

Таблица 1.2
(дәвамы)

| Продукция берәмлегенә беренчел чимал, материаллар чыгымы нормасы | | | | | | | Җитештерү калдыклары барлыкка килү микъдаре (күләме) ($Н_о \cdot q_i$) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Үлчәү берәмлеге | | Чыгым нормасы зурлыгы (N) | Чималның, материалларның чиста чыгымы (Р) | Кире кайтаргысыз югалышлар ($Н_п$) | Югалтулар коэффициенты ($К_п$) | Җитештерү калдыгы барлыкка килү нормативы ($Н_о$) | Микъдар | Үлчәү берәмлеге | |
| Атама | Код | | | | | | | Атама | Код |
| 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 |

**1, 2 графаларда** продукция җитештерү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган калдыкның атамасын һәм Калдыкларны классификацияләүнең федераль каталогы (ФККО) буенча кодын күрсәтергә.

**3, 4 графаларда** чыгарыла торган продукциянең атамасын һәм “Продукциянең Гомумроссия классификаторы” (ОКП) буенча кодын күрсәтергә.

**5 графада** чыгарыла торган продукциянең планлаштырыла торган микъдарен (күләмен) күрсәтергә ($q_i$).

**6, 7 графаларда** чыгарыла торган продукциянең атамасын һәм “Үлчәү берәмлекләренең Гомумроссия классификаторы” (ОКЕИ) буенча үлчәү берәмлеге кодын күрсәтергә.

**8, 9 графаларда** әлеге продукцияне җитештерү өчен файдаланыла торган чимал һәм материалларның атамасын һәм “Продукциянең Гомумроссия классификаторы” (ОКП) буенча кодын күрсәтергә.

**10, 11 графаларда** беренчел чимал, материаллар чыгымы нормасы атамасын һәм үлчәү берәмлеге кодын (N), чимал һәм материалларның чиста чыгымын (Р), кире кайтаргысыз югалтуларны ($Н_п$), җитештерелә торган продукция берәмлегенә

калдыклар барлыкка килү нормативын ($Н_о$) “Үлчәү берәмлекләренең Гомумроссия классификаторы”ннан (ОКЕИ) күрсәтергә.

**12 графада** җитештерелә торган продукция берәмлегенә беренчел чимал, материал чыгымы нормасы зурлыгын күрсәтергә (N).

**13 графада** продукция берәмлегенә чимал һәм материалның чиста чыгымын күрсәтергә.

**14 графада** продукция берәмлегенә чимал һәм материалларның кире кайтаргысыз югалышларын күрсәтергә ($Н_п$).

**12, 13, 14 графалар** технологик карталар, продукция берәмлегенә чимал, материаллар чыгымы нормаларының җыелма ведомостьлары мәгълүматлары нигезендә технологик хезмәтләр тарафыннан тутырыла. Химия, микробиология, азык-төлек сәнәгатендә беренчел документлар сыйфатында продукция җитештерүнең технологик регламентлары файдаланыла.

**15 графада** котылгысыз кире кайтаргысыз югалышлар коэффициентын ($К_п$) күрсәтергә, ул түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К_п = Н_п / N,$$

анда $Н_п$ - җитештерү процессында чимал һәм материалларның котылгысыз кире кайтаргысыз югалышлары;

N - продукция берәмлегенә чимал, материаллар чыгымы нормасы.

**16 графада** җитештерү калдыклары барлыкка килү нормативын ($Н_о$) күрсәтергә, ул түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Н_о = N(1 - К_п) - Р,$$

анда N - продукция берәмлегенә чимал, материаллар чыгымы нормасы; $К_п$ - котылгысыз кире кайтаргысыз югалышлар коэффициенты;

Р – чимал һәм материалларның чиста (файдалы) чыгымы.

**17 графада** калдык барлыкка килү микъдарен (күләмен) күрсәтергә, ул продукция берәмлеген җитештерү нәтиҗәсендә барлыкка килгән калдык барлыкка килү нормативының ($Н_о$) чыгарыла торган продукциянең планлаштырыла торган микъдаренә (күләменә) ($q_i$)тапкырчыгышы буларак исәпләнә.

**18, 19 графаларда** калдык барлыкка килү күләмен үлчәү берәмлеген һәм “Үлчәү берәмлекләренең Гомумроссия классификаторы”ннан (ОКЕИ) аның кодын күрсәтергә.

## Үрнәк 1.3.
## Калдыклар барлыкка килүнең группа нормативын һәм калдыклар барлыкка килүнең суммар күләмен исәпләү

| Калдык төре | | Җитештерү калдыклары барлыкка килүнең группа нормативы ($Н_{о\ гр.}$) | | | Калдыклар барлыкка килүнең гомуми күләме ($\Sigma Н_о \cdot q_i$) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Атама | ФККО буенча код | Зурлык | Үлчәү берәмлеге | | Микъдар | Үлчәү берәмлеге | |
| | | | Атама | Код | | Атама | Код |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |

1.3 таблицаны тутырганда, төрле продукция җитештергәндә бер үк төрле калдык барлыкка килү вариантлары булырга мөмкин. Андый очракларда калдыклар барлыкка килүнең гомуми (суммар) күләмен исәпләргә кирәк:

$$\sum_{i=1}^{m} N_i \cdot q_i ,$$

шулай ук калдыклар барлыкка килүнең группа нормативын ($Н_{о\ гр.}$), түбәндәге формула буенча:

$$Н_{о\ гр.} = \frac{\sum_{i=1}^{m} N_i \cdot q_i - \sum_{i=1}^{m} (Р_i + Н_{mi})\, q_i}{\sum_{i=1}^{m} q_i} ,$$

анда $q_i$ - продукция чыгару күләме;

i – җитештерелә торган продукция төренең индексы (1=1, 2....m).

## Үрнәк 1.4.
## Файдаланыла торган чимал берәмлегенә карата билгеләнә торган калдыклар барлыкка килү нормативларын исәпләүле-аналитик алым белән исәпләү

| Калдык төре | | Җитештерү | | Технологик процесс | | Беренчел чимал | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Атама | ФККО буенча код | Атама | Код | Атама | Код | Атама | ОКП буенча код | Аны эшкәрткәндә калдыклар барлыкка килә торган чимал күләме ($Q_c$) | | |
| | | | | | | | | Зурлык | Үлчәү берәмлеге | |
| | | | | | | | | | Атама | Код |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |

Үрнәк 1.4
(дәвамы)

| Чимал берәмлегенә беренчел чимал, материаллар чыгымы нормасы | | | | | | Калдыклар барлыкка килү нормативы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Үлчәү | Чыгым | Чимал- | Кире | Югалыш | Беренчел | натураль үлчәү |

| берәмлеге | | нормасы зурлыгы (N) | ның, матери-аллар-ның чиста чыгымы (Р) | кайтаргы-сыз югалыш-лар ($Н_п$) | -лар коэффи-циенты ($К_п$) | чималны, материалларны файдалану коэффициеты ($К_{исп}$) | берәмлекләрендә ($Н_о$) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Атама | Код | | | | | | Зур-лык | Үлчәү берәмлеге | |
| | | | | | | | | Атама | Код |
| 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 |

Таблица 1.4
(дәвамы)

| Калдыклар барлыкка килү нормативы ($Н_о$) | | | Калдыклар барлыкка килү микъдаре (күләме) ($V_о$) | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Зурлык | Үлчәү берәмлеге | | Зурлык | Үлчәү берәмлеге | |
| | Атама | Код | | Атама | Код |
| 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 |

**1, 2 графаларда** чималны, материалларны файдалану нәтиҗәсендә барлыкка килә торган калдыкның атамасын һәм Калдыкларның федераль классификация каталогына (ФККО) туры китереп кодын күрсәтергә.

**3 графада** анда калдыклар барлыкка килә торган производство атамасын күрсәтергә.

**4, 6 графаларда** машина эшкәртүе өчен (булган очракта) кодлар күрсәтергә.

**5 графада** калдыклар барлыкка килә торган технологик процесс атамасын күрсәтергә.

**7, 8 графаларда** әлеге продукцияне җитештерү өчен файдаланыла торган чималның, материалның атамасын һәм кодын “Продукциянең Гомумроссия классификаторы” (ОКП) буенча кодын күрсәтергә.

**9 графада** файдаланыла торган материалның микъдарен (күләмен) күрсәтергә.

**10, 11 графаларда** файдаланыла торган чималны, материалны үлчәү берәмлегенең атамасын һәм “Үлчәү берәмлекләренең Гомумроссия классификаторы” (ОКЕИ) буенча кодын күрсәтергә.

**12, 13 графаларда** җитештерелә торган продукция берәмлегенә беренчел чимал (материаллар) чыгымы нормасын (N), чималны һәм материалларның чиста чыгымын (Р), кире кайтаргысыз югалышлар ($Н_п$), җитештерү калдыгы барлыкка килү нормативын ($Н_о$) үлчәү берәмлеге атамасын һәм “Үлчәү берәмлекләренең Гомумроссия классификаторы” (ОКЕИ) буенча кодын күрсәтергә.

**14 графада** файдаланыла торган чимал берәмлегенә беренчел чимал, материал чыгымы нормасы зурлыгын күрсәтергә (N).

**15 графада** продукция берәмлегенә чимал һәм материалларның чиста чыгымын күрсәтергә (Р).

**16 графада** продукция берәмлегенә чимал һәм материалларның кире кайтаргысыз югалышын күрсәтергә ($Н_п$).

**14, 15, 16 графалар** технологик карталар, продукция берәмлегенә чимал, материаллар чыгымы нормаларының җыелма ведомостьлары мәгълүматлары нигезендә технологик хезмәтләр тарафыннан тутырыла. Химия, микробиология, азык-төлек сәнәгатендә беренчел документлар сыйфатында продукция җитештерүнең технологик регламентлары файдаланыла.

**17 графада** кире кайтаргысыз югалышлар коэффициентын ($К_п$) күрсәтергә, ул түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К_п = Н_п / N,$$

анда $Н_п$ - җитештерү процессында чимал һәм материалларның котылгысыз кире кайтаргысыз югалышлары;

N - чимал, материаллар чыгымы нормасы.

**18 графада** чимал файдалану коэффициентын күрсәтергә ($К_{исп}$):

$$К_{исп} = \frac{P}{N},$$

анда P – чимал, материалларның чиста чыгымы;

N - чимал, материаллар чыгымы нормасы.

**19 графада** калдыклар барлыкка килү нормативын ($Н_о$) күрсәтергә, ул түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$Н_о = N(1 - К_п) - P,$$

анда N – продукция берәмлегенә чимал, материаллар чыгымы нормасы;

P - чимал, материалларның чиста (файдалы) чыгымы;

$К_п$ - котылгысыз кире кайтаргысыз югалышлар коэффициенты.

**20, 21 графаларда** калдык барлыкка килү нормативын ($Н_о$) үлчәү берәмлеге атамасын һәм “Үлчәү берәмлекләренең Гомумроссия классификаторы” (ОКЕИ) буенча кодын күрсәтергә.

**22 графада** калдык барлыкка килү нормативы зурлыгын процентларда күрсәтергә ($Н_о$)

$$Н_о = 1 - К_{исп} - К_п,$$

анда $К_{исп}$ - чимал, материаллар файдалану коэффициенты;

$К_п$ - котылгысыз кире кайтаргысыз югалышлар коэффициенты;

**23, 24 графаларда** калдык барлыкка килү күләмен үлчәү берәмлеге атамасын һәм “Үлчәү берәмлекләренең Гомумроссия классификаторы”ннан (ОКЕИ) кодын күрсәтергә.

**25 графада** калдык барлыкка килү микъдарен (күләмен) ($V_o$) күрсәтергә, ул чимал файдалану нәтиҗәсендә барлыкка килгән калдык барлыкка килү нормативының ($H_o$) файдаланыла торган чимал, материаллар күләменә (микъдаренә) ($Q_c$) тапкырчыгышы буларак исәпләнә

$$V_o = Q_c \cdot H_o,$$

анда $Q_c$ - файдаланыла торган чимал, материаллар күләме;

$H_o$ - калдык барлыкка килү нормативы.

**26, 27 графаларда** калдык барлыкка килү микъдарен (күләмен) исәпләү берәмлеге атамасын һәм “Үлчәү берәмлекләренең гомумроссия классификаторы”ннан (ОКЕИ) кодын күрсәтергә.

**Үрнәк 1.5.**
**Беренчел мәгълүматлар һәм калдыклар барлыкка килү нормативын статистик алым белән исәпләү нәтиҗәләре**

| Чимал, материаллар | | | | | Продукция | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| атама | аны эшкәрткәндә калдыклар барлыкка килә торган чимал микъдаре (күләме) (Ос) | | | | атама | чыгарыла торган продукция микъдаре (Опр) | | | |
| | үлчәү берәмл. | зурлык | | | | үлчәү берәмл. | зурлык | | |
| | | 20_ ел | 20_ ел | 20_ ел | | | 20_ ел | 20_ ел | 20_ ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |

Үрнәк 1.5.
Таблицаның дәвамы

| Калдык төре | | Калдыклар барлыкка килү микъдаре (күләме) (Vo) | | | | Калдыклар барлыкка килүнең еллар буенча чагыштырма микъдаре | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| атамасы | ФККО буенча код | зурлык | | | Үлчәү берәмл. | зурлык | | | Үлчәү берәмл. |
| | | 20_ ел | 20_ ел | 20_ ел | | 20_ ел | 20_ ел | 20_ ел | |
| 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |

## 1.5. таблицаны тутыру буенча КҮРСӘТМӘЛӘР

**1 графада** аларны эшкәрткәндә калдыклар барлыкка килә торган чималның яки материалларның атамасын күрсәтәләр;

**2 графада** продукция җитештергәндә чималның яки материалларның күләмен үлчәү берәмлеге атамасын күрсәтәләр;

**3, 4, 5 графаларда** продукция җитештергәндә файдаланылган чималның яки материалларның микъдарен карала торган чор өчен еллар буенча күрсәтәләр;

**6 графада** аны җитештергәндә калдыклар барлыкка килә торган продукция атамасын күрсәтәләр;

**7 графада** продукцияне үлчәү берәмлеге атамасын күрсәтәләр;

**8-10 графаларда** аны җитештергәндә калдыклар барлыкка килә торган продукция микъдарен карала торган чор өчен еллар буенча күрсәтәләр;

**11, 12 графаларда** чимал эшкәртү нәтиҗәсендә яки продукция җитештергәндә барлыкка килгән калдыкның атамасын һәм калдыкның ФККО буенча кодын күрсәтәләр;

**13-15 графаларда** калдыклар барлыкка килү микъдарен (күләмен) карала торган чор өчен еллар буенча күрсәтәләр;

**16 графада** барлыкка килгән калдыкның микъдарен үлчәү берәмлеге атамасын күрсәтәләр;

**17-19 графаларда** калдыклар барлыкка килүнең чагыштырма микъдаре зурлыгын продукция берәмлегенә мөнәсәбәттә карала торган чор өчен еллар буенча күрсәтәләр;

**20 графада** калдыклар барлыкка килүнең чагыштырма микъдарен үлчәү берәмлеге атамасын күрсәтәләр

Калдыклар барлыкка килү нормативлары
һәм аларны урнаштыруга лимитлар
проектларын эшләү буенча
методик күрсәтмәләргә
Кушымта 2

**Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын рәсмиләштерү өчен**

**ҮРНӘКЛӘР**

**Үрнәк 2.1.**

**Титул бите**

Код ОКПО ________

Оешма җитәкчесе яки шәхси эшмәкәр

__________ / ______________ /
(имза) (имзага расшифровка)

" ___ " _________ 20 __ ел

М.У. (булган очракта)

Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проекты (КБНУЛП)

______________________________________________________
(Юридик затның атамасы яки шәхси эшмәкәрнең Ф.И.О.)

______________________________________________________
(Территориаль аерымланган бүлекчәнең (филиалның) атамасы)

урнашу урыны (шәһәр, бистә)

ел

## Үрнәк 2.2

## Продукция җитештерү буенча калдыклар барлыкка килүле эшчәнлеккә характеристика

| т/б N | Процессның атамасы | Чимал, материаллар | Продукция | “Калдык” халәтенә күчә торган матдәләр, материаллар, эшләнмәләр | Калдыкны бетерү буенча операцияләр |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

## Үрнәк 2.3.

## Продукция җитештерүгә хезмәт күрсәтү һәм тәэмин итү буенча калдыклар барлыкка килүле эшчәнлеккә характеристика

| т/б N | Эшчәнлек төре | Гамәлгә ашырыла торган эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр | “Калдык” халәтенә күчә торган матдәләр, материаллар, эшләнмәләр | Калдыкны бетерү буенча операцияләр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

## Үрнәк 2.4.

## Социаль инфраструктура объектларының калдыклар барлыкка килүле эшчәнлегенә характеристика

| т/б N | Эшчәнлек төре | Гамәлгә ашыыла торган эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр | “Калдык” халәтенә күчә торган матдәләр, материаллар, эшләнмәләр | Калдыкны бетерү буенча операцияләр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |

## Үрнәк 2.5.

## Алар өчен еллык барлыкка килү нормативы билгеләнә торган калдыклар исемлеге

| Калдык барлыкка китерә торган эшчәнлек төре, процесс | Калдык төре атамасы | Калдыкның ФККО буенча коды | Куркынычлык классы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |

## 2.5 үрнәкне тутыру буенча КҮРСӘТМӘЛӘР

**1 графада** калдык барлыкка китерә торган эшчәнлек төрен, процессны күрсәтәләр.

**2-4 графаларда** калдыкның ФККО буенча кодын һәм кодка туры килә торган калдык төре атамасын, куркынычлык классын күрсәтәләр.

### Үрнәк 2.6.

### Калдыкларның составы һәм физик-химик үзлекләре

<table>
<tr><td rowspan="2">т/б N</td><td rowspan="2">Калдык төре атамасы</td><td rowspan="2">Калдык барлыкка китерә торган эшчәнлек төре, процесс</td><td rowspan="2">ФККО буенча код</td><td rowspan="2">Куркыныч -лык классы</td><td rowspan="2">Куркыныч үзлекләре</td><td colspan="3">Калдыкның физик-химик үзлекләре</td></tr>
<tr><td>Агрегат халәте</td><td>Компонент -лар атамасы</td><td>Компонент-лар микъдаре, %</td></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td><td>6</td><td>7</td><td>8</td><td>9</td></tr>
</table>

### Үрнәк 2.7.

### Агынты суларны чистарту корылмалары характеристикасы

<table>
<tr><td colspan="7">Чистарту корылмасының, җайланмасының атамасы</td></tr>
<tr><td colspan="7">Чистарту алымы</td></tr>
<tr><td colspan="7">Чистартуга керә торган пычраткыч матдәләрнең исемлеге һәм составы</td></tr>
<tr><td>т/б N</td><td>Пычраткыч матдәләрнең атамасы (ПМ)</td><td>Чистартуга керә торган ПМ концентрациясе</td><td>Концентрация үлчәү берәмл.</td><td>Чистартылу дәрәҗәсе, %</td><td>Куәт, $м^3$ /сәгать</td><td>Эшләү вакыты, бер елга сәгатьләр</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

<table>
<tr><td colspan="5">Барлыкка килә торган калдыклар исемлеге</td></tr>
<tr><td>т/б N</td><td>Калдык төре атамасы</td><td>Калдыкның ФККО буенча коды</td><td>Куркынычлык классы</td><td>Калдык барлыкка килүнең еллык нормативы, т/ел</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
</table>

### Үрнәк 2.8.

## Су әзерләү өчен җайланмаларның яки җиһазның характеристикасы

<table>
<tr><td colspan="7">Су әзерләү өчен җайланма яки җиһазның атамасы</td></tr>
<tr><td colspan="7">Тип (марка)</td></tr>
<tr><td colspan="7">Чистарту алымы</td></tr>
<tr><td colspan="7">Бетерелергә тиешле матдәләрнең исемлеге һәм составы</td></tr>
<tr><td>т/б N</td><td>Бетерелергә тиешле матдәнең атамасы</td><td>Бетерелергә тиешле матдәнең концентрациясе</td><td>Концентрация үлчәү берәмл.</td><td>Чистарту дәрәҗәсе, %</td><td>Куәт, $м^3$ /сәгать</td><td>Эшләү вакыты, елга сәгатьләр</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="7">Барлыкка килә торган калдыклар исемлеге</td></tr>
<tr><td>т/б N</td><td colspan="2">Калдык төре атамасы</td><td>Калдыкның ФККО буенча коды</td><td colspan="2">Куркынычлык классы</td><td>Калдык барлыкка килүнең еллык нормативы, т/ел</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="2"></td><td></td><td colspan="2"></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td colspan="2"></td><td></td><td colspan="2"></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td colspan="2"></td><td></td><td colspan="2"></td><td></td></tr>
</table>

**Үрнәк 2.9.**

## Тузан тотып кала торган һәм газчистарткыч җайланмалар (ТГҖ) һәм җиһаз храктеристикасы

<table>
<tr><td colspan="7">ТГҖ, җиһаз атамасы</td></tr>
<tr><td colspan="7">Чистарту алымы</td></tr>
<tr><td colspan="7">Тотылып калына торган пычраткыч матдәләрнең исемлеге һәм составы</td></tr>
<tr><td>т/б N</td><td>Пычраткыч матдәләрнең (ПМ) атамасы</td><td>Чистартылуга кирә торган ПМ концентрация-се</td><td>Концен-трация үлчәү берәмл.</td><td>Чистартылу дәрәҗәсе, %</td><td>Җитештерүчән-лек, $м^3$ /сәгать</td><td>Эшләү вакыты, елга сәгатьләр</td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td><td></td></tr>
<tr><td colspan="7">Барлыкка килә торган калдыклар исемлеге</td></tr>
<tr><td>т/б N</td><td colspan="2">Калдык төре атамасы</td><td>Калдыкның ФККО буенча коды</td><td colspan="2">Куркынычлык классы</td><td>Калдык барлыкка килүнең еллык нормативы, т/ел</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="2"></td><td></td><td colspan="2"></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td colspan="2"></td><td></td><td colspan="2"></td><td></td></tr>
<tr><td></td><td colspan="2"></td><td></td><td colspan="2"></td><td></td></tr>
</table>

**Үрнәк 2.10.**

## Җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килүнең еллык нормативлары

| т/б N | Калдык төре атамасы | ФККО буенча код | Куркыныч-лык классы | Калдык барлыкка китерә торган эшчәнлек төре, процесс* | Калдык барлыкка килүнең еллык нормативы, т |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| | I класс куркынычлыклылар барлыгы: | | | | |
| | | | | | |
| | II класс куркынычлыклылар барлыгы: | | | | |
| | | | | | |
| | III класс куркынычлыклылар барлыгы: | | | | |
| | | | | | |
| | IV класс куркынычлыклылар барлыгы: | | | | |
| | | | | | |
| | V класс куркынычлыклылар барлыгы: | | | | |
| | | | | | |
| | Бөтенесе: | | | | |

*Калдыклар барлыкка килү чыганакларын инвентаризацияләү нәтиҗәләре нигезендә

## Үрнәк 2.11.

## Калдыкларның операция хәрәкәте схемасы

| т/б N | ФККО буенча код | Калдык төре атамасы | Куркынычлык классы | 20_ ел башына калдыкларның булуы, т | Калдык барлыкка килүнең еллык нормативы, т | Ел дәвамында чит оешмалардан калдыклар алу | | Ел дәвамында калдыкларны үз предприятиесендә утильләштерү һәм зарарсызлау | | Ел дәвамында калдыкларны чит оешмаларга тапшыру | | Калдыкларны урнаштыру яки туплау | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Микъдар, т | Кабул итү максаты | Микъдар, т | Утильләштерү юнәлеше | Микъдар, т | Тапшыру максаты | Микъдар, т | Урнаштыру яки туплау буенча операция | Урнаштыру яки туплау объектының инв.номеры |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |

## 2.11 үрнәкне тутыру буенча
## КҮРСӘТМӘЛӘР

**1 графада** таблицада язуның тәртип номерын күрсәтәләр;

**2-4 графаларда** ФККО буенча кодын һәм кодка туры килә торган калдык төре атамасын, куркынычлык классын күрсәтәләр;

**5 графада** ел башына КБНУЛП эшләү датасына калдыклар барлыгын тонналарда күрсәтәләр;

**6 графада** калдыклар барлыкка килүнең еллык нормативын тонналарда күрсәтәләр;

**7 графада** чит оешмалардан алу паланлаштырыла торган калдыклар микъдарен тонналарда күрсәтәләр;

**8, 12 графаларда** түбәндәге исемлектән калдыклар кабул итү\тапшыру максатын күрсәтәләр:

- утильләштерү;
- эшкәртү;
- зарарсызландыру (шул исәптән яндырып юк итү);
- күмү;
- саклау;

**9 графада** үз предприятиесендә утильләштерелергә һәм зарарсызландырылырга тиешле калдыклар микъдарен тонналарда күрсәтәләр;

**10 графада** утильләштерү һәм зарарсызландыру юнәлешен түбәндәге исемлектән күрсәтәләр:

- чимал сыйфатында файдалану;
- регенерация;
- кыйммәтле компонентлар аерып алу;
- ягулык сыйфатында файдалану (яндырып юк итүдән тыш);
- ашлама сыйфатында файдалану;
- майлагыч сыйфатында файдалану;
- юлларга, сәнәгать мәйданчыкларына һ.б.ш. бушату һәм ныгыту;
- зарарсызландыру (термик алымнар файдаланмыйча);
- термик алымнар белән зарарсызландыру;
- бүтәннәр (күрсәтергә);

**11 графада** чит оешмаларга тапшыру планлаштырыла торган калдыклар микъдарен тонналарда күрсәтәләр;

**13 графада** урнаштыру яки туплауга планлаштырыла торган калдыклар микъдарен тонналарда күрсәтәләр;

**14 графада** калдыкларны урнаштыру яки туплау буенча операцияләрне түбәндәге исемлектән күрсәтәләр:

- 11айга кадәр срок белән саклау;
- 11айдан артык срок белән саклау;
- күмү;

**15 графада** калдыкларны урнаштыру яки туплау объектының инвентарь номерын күрсәтәләр.

**Үрнәк 2.12.**

**Оешмалар - калдыкларны китереп торучылар һәм кулланучылар турында реквизитлар (мәгълүматлар)**

| Калдык турында мәгълъматлар | | | | Кабул итү/тапшыру максаты | Калдыкларны китереп торучыларның һәм кулланучыларның реквизитлары | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| т/б N | Калдык атамасы | Калдык -ның ФККО буенча коды | Куркынычлык классы | | Оешма төре | Оешма атамасы | Оешма адресы | ИНН | договор N | Лицензия N |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |

**2.12 үрнәкне тутыру буенча**

**КҮРСӘТМӘЛӘР**

**1 графада** таблицада язуның тәртип номерын күрсәтәләр;

**2-4 графаларда** калдыкның ФККО буенча кодын һәм кодка туры килә торган калдык төре атамасын һәм куркынычлык классын күрсәтәләр;

**5 графада** калдыклар кабул итү\тапшыру максатын һәр китереп торучы һәм кулланучы өчен аерым күрсәтәләр:

- утильләштерү;
- эшкәртү;
- зарарсызландыру (шул исәптән яндырып юк итү);
- күмү;
- саклау;

**6 графада** оешма төрен – китереп торучы (ПС хәрефләре куела) яки кулланучыны (ПР хәрефләре куела) күрсәтәләр;

**7 графада** әлеге төр калдыкны китереп торучының яки кулланучының тулы атамасын күрсәтәләр (договорлар яки бухгалтерлык исәбе документлары нигезендә тутырыла);

**8 графада** әлеге төр калдыкны китереп торучының яки кулланучының фактик урнашкан урыны адресын күрсәтәләр;

**9 графада** калдыкны китереп торучының яки кулланучының ИНН күрсәтәләр (бухгалтерлык исәбе документлары нигезендә тутырыла); чит илләр оешмалары өчен кодлар куелмый, ләкин адреста оешманың урнашу иле күрсәтелә;

**10 графада** калдыкны кабул итү/тапшыру аның буенча гамәлгә ашырыла торган договор номерын (булган очракта) күрсәтәләр;

**11 графада** I - IV класс куркынычлыктагы калдыкларны җыю, транспортта ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру буенча эшчәнлеккә лицензия номерын күрсәтәләр.

## Үрнәк 2.13.

## Калдыкларны утильләштерү/ зарарсызландыру объекты характеристикасы

Инвентаризация үткәрү датасы ___________ 20 ___ ел.

Бит ________ Битләр ____________

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. Объектның инв. номеры | | 2. Объектның билгеләнеше | | (код) |
| 3. Урнашуы | | 4. Объектның урнашу территориясе ОКАТО | | (код) |
| 5. Объект атамасы (производство, цех, җайланма, участок): | | | | |
| 6. Калдыкларны утильләштерү, зарарсызландыру яки юк итү технологиясе атамасы: | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7.1 Объектка проект булу | | 7.2 ДЭЭ уңай бәяләмәсе | | 7.3 Дата | | 7.4 Номер | |
| 7.5 ДЭЭ органы атамасы: | | | | | | | |
| 8. Санитария-саклау зонасы үлчәме, м | | | | | | | |

9. Утильләштерелә, зарарсызландырыла яки юк ителә торган калдыкларның төрләре һәм микъдаре:

| 9.1 ФККО буенча код | 9.2 Калдыкның атамасы | 9.3 Куәт | |
|---|---|---|---|
| | | т/ел | $м^3$ /ел |
| | | | |
| | | | |

10. Калдыкларны утильләштерү белән алынган продукция исемлеге

| 10.1 ОКП коды | 10.2 Продукция атамасы | 10.3 Сертификат булу |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

11. Барлыкка килә торган калдыклар исемлеге:

| 11.1 ФККО буенча код | 11.2 Калдыкның атамасы |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

12. Объектта әйләнә-тирә мохит мониторингы төрләре:

| 12.1 Мониторинг төре атамасы | | 12.2 ӘМ сыйфаты нормативларын саклау |
|---|---|---|
| | (код) | |

___________________________________________

Юридик затның тулы (һәм кыскартылган) атамасы (шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

___________________________________________

Юридик затның урнашкан урыны (шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны)

ОГРН _________________ ИНН _______________ ОКВЭД ______________ ОКПО ______________

Почта адресы, телефон, факс, e-mail ___________________________________

Юридик затның җитәкчесе
(шәхси эшмәкәр) __________________ ________________________

(имза) (ФИО)

МУ (булган очракта) " _____ " ___________ 20 ___ ел.

## 2.13 үрнәкне тутыру буенча
## КҮРСӘТМӘЛӘР

**1 графада** калдыкны утильләштерү яки зарарсызландыру (юк итү) объектының (җайланманың) инвентарь номерын күрсәтәләр; әгәр инвентарь номеры булмаса, ул утильләштерү яки зарарсызландыру (юк итү) объектларына бердән башлап алга таба тәртип буенча бирелә.

**2 графага** объектның билгеләнеше һәм аның коды языла, аларны 1 таблицадан сайлыйлар.

Таблица 1

| объектның билгеләнеше | Машина эшкәртүе өчен код |
|---|---|
| чимал яки чималга өстәмәләр сыйфатында файдалану | 01 |
| регенерация (торгызу) | 02 |
| кыйммәтле компонентлар аерып алу | 03 |
| ягулык сыйфатында файдалану (яндырып юк итүдән тыш) | 04 |
| продукция алып, биологик эшкәртү (мәсәлән, компостлаштыру) | 05 |
| алдарак исәпкә алынмаган физик-химик эшкәртү (мәсәлән, пешекләү, киптерү, тишү, нейтральләштерү, тондыру һ.б.) | 06 |
| аннан соң файдалану өчен ваклау | 07 |
| аннан соң файдалану өчен сортировка | 08 |
| биохимик зарарсызландыру | 09 |
| реагентлы (химик) зарарсызландыру | 10 |
| термик зарарсызландыру, шул исәптән яндырып юк итү | 11 |
| башкасы (күрсәтергә) | 99 |

**3 графада** объектның урнашу вариантларының берсен күрсәтәләр:

- төп җитештерү территориясендә;
- махсус бүлеп бирелгән территориядә.

**4 графада** объектныңурнашу территориясенең ОКАТО кодын (беренче 5 билге) күрсәтәләр.

**5 графада** аның кысаларында калдыкларны утильләштерү яки зарарсызландыру (юк итү) объектлары эшли торган производство атамасын, шулай ук объектның (җайланманың) үзенең атамасын күрсәтәләр

**6 графага** калдыкларны утильләштерү/зарарсызландыру (юк итү) технологиясе яки чарасы атамасын кертәләр; атама кулланыла торган технологиянең яки чараның асылын чагылдырырга тиеш.

**7.1 графада** әлеге объектка проектның булуын күрсәтәләр (бар, юк).

**7.2 -7.5 графаларда** дәүләт экологик экспертизасының әлеге объектка проект буенча уңай карары булуын күрсәтәләр (бар, юк); дәүләт экологик

экспертизасының уңай бәяләмәсен биргән орган атамасы, документ реквизитлары.

**8 графада** аерымланган территориядә урнашкан объектлар өчен санитария-саклау зонасы булуын һәм аның үлчәмен метрларда күрсәтәләр.

**9.1 - 9.3 графаларда** аерым юлда калдыкларның ФККО буенча кодларын һәм атамаларын санап чыгалар, алар, регламентка туры китереп, әлеге объектта утильләштерелгән яки зарарсызландырылган (юк ителгән) булырга мөмкин, шулай ук әлеге объектның санап кителгән калдыклар төрләренең һәркайсын файдалану яки зарарсызландыру буенча проект куәтенең сан күрсәткечен, т/ел һәм $м^3$/ел күрсәтәләр.

**10.1 – 10.3 графаларда** аерым юлда әлеге объектта калдыклар файдаланып җитештерелә торган продукциянең ОКП буенча кодларын һәм атамаларын санап чыгалар, шулай ук күрсәтелгән продукциягә алынган куркынычсызлык яки ярашлылык сертификатларының реквизитларын китерәләр.

**11.1-11.2 графаларда** әлеге объектның эшләү процессында продукция алганда яки калдыкларны зарарсызландырганнан соң барлыкка килә торган калдыкларның ФККО буенча кодларын һәм атамаларын китерәләр.

**12.1 графада** аерым юлда, 2 таблицага туры китереп, объектны эксплуатацияләү белән бәйле рәвештә алып барыла торган әйләнә-тирә табигый мохит мониторингы төрләрен һәм аларның кодларын кертәләр (санап чыгалар).

Таблица 2

| Әйләнә-тирә мохит мониторингы төрләре | Машина эшкәртүе өчен код |
|---|---|
| грунт сулары мониторингы (күзәтү скважиналары) | 01 |
| өске катлам сулар мониторингы | 02 |
| туфрак катламы мониторингы | 03 |
| атмосфера һавасы мониторингы | 04 |
| атмосфера явымнары мониторингы | 05 |
| мониторинг юк | 99 |

**12.2 графада** әйләнә-тирә мохитнең һәр компоненты өчен экологик мониторингның гомумиләштерелгән нәтиҗәләрен китерәләр; язуларны кертү вариантлары түбәндәгечә:

- әйләнә-тирә мохит сыйфатының билгеләнгән нормативларын арттыру юк;
- аерым күрсәткечләр буенча арттырулар күзәтелә;
- күп күрсәткечләр буенча арттырулар күзәтелә.

**Үрнәк 2.14.**

## Калдыкларны 11 айга кадәр срок белән туплау объектлары характеристикасы. Калдыклар туплануның иң зур чик күләмен нигезләү

| Калдыклар туплау объекты характеристикасы | | | | | | Туплана торган калдык характеристикасы | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Инв. N | Объект тибы | Гомуми мәйданы, $м^3$ | Объект корылышы | Сыйдырышлыгы | | Калдык төре атамасы | ФККО буенча код | Куркынычлык классы | Калдык туплау ысулы | Саклау срогы, көннәр, ай, ел | Туплану срогын билгеләү өчен нигез | Калдык барлыкка килүнең еллык нормативы | Калдыклар туплануның иң зур чик күләме | |
| | | | | т | $м^3$ | | | | | | | т | т | $м^3$ |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |

Калдык туплау объекты тибы, төре, шулай ук калдык төрен туплау ысулы таблицада кыскартылма рәвешендә бирелергә мөмкин, материалны бәян итү текстында кыскартылма расшифровкаланган шартта.

## 2.14 үрнәкне тутыру буенча
## КҮРСӘТМӘЛӘР

**1 графада** калдыклар туплау объектының инвентаризация нәтиҗәләре буенча бирелгән инвентарь номерын күрсәтәләр.

**2 графада** калдыклар туплау объектының тибын күрсәтәләр, ул түбәндәге исемлектән сайлана:

- бина (яки аның өлеше);
- каплаулы мәйданчык;
- ачык мәйданчык;
- стационар сыешлык.

**3 графада** объектның гомуми мәйданын $м^2$ күрсәтәләр;

**4 графада** объектның корылышын түбәндеге исемлекне файдаланып күрсәтәләр:

Биналар өчен:

- бина таш;
- бина агач;
- диварлар буяу белән буялган;
- грунт идән;
- бетон яки асфальт-бетон идән;
- агач идән;
- табигый җилләтү;
- мәҗбүри җилләтү;
- тәрәзәләрдә рәшәткәләр булу;
- ишекләрдә йозаклар булу;
- авария ситуацияләрен ликвидацияләү өчен чараларның булуы;
- башкасы (күрсәтергә).

Калган объектлар өчен:

- грунт нигез;
- асфальт-бетон нигез;
- киртә;
- валлар белән әйләндереп алу;
- тузанга каршы җайланма булу;
- яңгыр суларын җыю;
- авария ситуацияләрен ликвидацияләү өчен чараларның булуы;
- башкасы (күрсәтергә);

**5-6 графаларда** объектның сыйдырышлыгын тонналарда һәм $м^3$ күрсәтәләр; бер типтагы объектлар өчен суммар сыйдырышлыкны күрсәтәләр;

**7- 9 графаларда** калдыкның ФККО буенча кодын һәм калдыкның кодка туры килә торган төрен һәм куркынычлык классын күрсәтәләр;

**10 графада** калдык туплау ысулы атамасын күрсәтәләр: әгәр калдык тарасыз тупланса, түбәндәге язуларның берсен сайлыйлар:

- тарасыз (өелеп, чәчелгән хәлдә һ.б.) башка калдыклардан аерым;
- тарасыз (өелеп, чәчелгән хәлдә һ.б.) башка калдыклар белән катнашмада;

әгәр калдык тарада тупланса, туплау чарасын һәм тара төрен (баллоннар, кисмәкләр, контейнерлар, аслыклар һ.б.ш.) һәм тара материалын (пыяла, агач, металл, полимер, кәгазь, катыргы һ.б.ш.) түбәндәге вариантларны файдаланып күрсәтәләр:

- ачык тарада аерым;
- ачык тарада катнашмада;
- ябык тарада аерым;
- ябык тарада катнашмада;
- герметиклаштырган тарада аерым;
- герметиклаштырган тарада катнашмада.

**11 графада** калдыкның туплану срогын күрсәтәләр: көннәр, ай, ел;

**12 графада** туплану срогын билгеләү өчен нигезне күрсәтәләр:

- санитария-гигиена, янгынга каршы һәм бүтән таләпләрне эченә алган, туплау срогы анең нигезендә билгеләнгән документ реквизитлары:
- утильләштерү/зарарсызландыру өчен партия формалаштыру;
- транспорт партиясе формалаштыру;
- калдыкның куркынычлык классын түбәнәйтү;
- калдыкның физик-химик характеристикалары үзгәрү (мәсәлән, төпкә утыру, суыну, табигый юл белән кибү һ.б.ш.);

**13 графада** калдык барлыка килүнең еллык нормативын тонналарда күрсәтәләр;

**14-15 графаларда** калдыклар туплауның иң зур чик микъдарен тонналарда һәм $м^3$ күрсәтәләр.

